КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 июнь г.Казань № 759

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү турында» 2013 ел, 17 июнь, 414 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү турында» 2013 ел, 17 июнь, 414 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 февраль, 131 нче; 2023 ел, 2 февраль, 83 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә мөмкин аерым категориядәге гражданнар исемлегенең һәм Татарстан Республикасында мондый кооперативлар әгъзалыгына кабул ителергә хокукы булган гражданнар исемлекләренә күрсәтелгән гражданнарны кертү нигезләренең 2.1 пунктындагы дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2008 елда Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерүгә субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 22 сентябрь, 708 нче карарын тормышка ашыру кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү хакында» 2008 ел, 31 декабрь, 940 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2009 елга, 2010 һәм 2011 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2009 ел, 14 гыйнвар, 1 0/1 нче карарының 5 пунктындагы егерме бишенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2009 ел, 24 декабрь, 880 нче карарының 5 пунктындагы егерме беренче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү концепциясен раслау турында» 2010 ел, 22 декабрь, 1091 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү» озак сроклы максатчан программасын раслау турында» 2011 ел, 20 июнь, 492 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү» озак сроклы максатчан программасын раслау турында» 2011 ел, 20 июнь, 492 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1113 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2012 елга Татарстан Республикасында ипотека кредитын үстерү» максатчан программасы турында» 2012 ел, 15 март, 214 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү» озак сроклы максатчан программасын раслау турында» 2011 ел, 20 июнь, 492 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 август, 739 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән аерым нормалары гамәлен туктатып тору турында» 2012 ел, 15 декабрь, 1091 нче карарына кушымтаның 10 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2015 елларда Татарстан Республикасында «Россия гражданнарына – һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак» өстенлекле илкүләм проектын тормышка ашыру турында» 2014 ел, 16 июль, 503 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин